**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«15» октябрь 2018 ел** **№ 301**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасы турында, 2016 елның 7 ноябрендәге 320 номерлы карары белән расланган «2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, "Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Азнакай муниципаль районы Уставына таянып **карар чыгарам:**

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасы турында, 2016 елның 7 ноябрендәге 320 номерлы карары белән расланган «2017-2021 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 Бүлек. "Программаның максатлары, бурычлары» түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба СЮКБО) финанс, мөлкәти, мәгълүмати, консультацион ярдәм күрсәтү механизмнарын җирле үзидарә органнары һәм халык арасында үзара хезмәттәшлекнең даими гамәлдәге системасын булдыру аша үстерү.»;

1.2. 5 Бүлек. «Төп программа чаралары системасы» түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1. СЮКБО хезмәткәрләрен һәм ирекле хезмәткәрләр әзерләү, яңадан аларның квалификациясен күтәрү өлкәсендә консультацион ярдәм күрсәтү;

- социаль юнәлешле СЮКБОга финанс ярдәме күрсәтү:

Азнакай муниципаль районы территориясендә проектларны гамәлгә ашыру максатларында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү, билгеләнгән гамәлгә кую документларын башкару кысаларында, түбәндәге юнәлешләр буенча:

1) гражданнарга социаль ярдәм һәм яклау;

2) әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннарны яклау;

3) гражданнарга һәм коммерциячел булмаган оешмаларга түләүсез яисә ташламалы нигездә юридик ярдәм күрсәтү һәм халыкны хокукый агарту, кеше һәм гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау эшчәнлеге;

4) мәгариф, агарту, фән, мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, гражданнарның сәламәтлеген профилактикалау һәм саклау өлкәсендәге эшчәнлек, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, гражданнарның әхлакый-психологик хәлен яхшырту, физик культура һәм спорт һәм күрсәтелгән эшчәнлеккә ярдәм күрсәтү, шулай ук шәхеснең рухи үсешенә ярдәм итү;

5) Россия Федерациясе гражданнарын патриотик, шул исәптән хәрби-патриотик, тәрбияләү өлкәсендә эшчәнлек;

- милләтара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү һәм этникара экстремизм күренешләрен профилактикалау;

- СЮКБО эшчәнлеген популярлаштыру.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
икътисад һәм финанслар буенча җитәкче
урынбасары Г.Г.Сөләйманова